| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ШИШИНЕРСКОРГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>25.03.2026 | **КАРАР**<br>№23 |

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының 2024 елның 16 июлендә 104 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2025 елның 29 декабрендәге 567-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Балтач районы прокуратурасының 12.03.2026 №02-08-01-2026 /Прдп102-26-209011 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге советының 2024 елның 16 июлендәге 104 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль хакындагы нигезләмәгә (29.11.2024 ел №115, 24.06.2025 ел № 135 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 нче пункт өстәргә:

«5) контрольдә тотыла торган зат әлеге статьяның 1 өлешендә каралган критерийларга туры килми.»;

1.2. 3.5.6 пунктта «контроль (күзәтчелек) чаралары,» сүзләрен «мәҗбүри профилактик визитлар,» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.5.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Мәҗбүри профилактик визитны үткәрү турында контрольдә тотыла торган затка «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә ул башланганчы егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

1.4. 3.5.1 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (региональ дәүләт контроле (күзәтчелек), федераль дәүләт контроле (күзәтчелек)

төрләренә һәм әлеге Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә каралган муниципаль контроль төрләренә карата , аларны гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган булса).»;

1.5. 3.5.1 пунктының 2 пунктчасында «муниципаль контроль» Исемлек» сүзләрен «муниципаль контроль» сүзләренә яисә белешмәләре урнаштыру чараларының классификацияләнгән реестрына кертелгән контроль астындагы затларга.Исемлек” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Салихҗанов